**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 529 11 июнь 2015 ел

"Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районында Татарстан Республикасында тәртип саклау җәмәгать пунктлары турында" 25.04.2015 № 33-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында

"Татарстан Республикасында тәртип саклауның җәмәгать пунктлары турында" 25.04.2015 № 33-ТРЗ һәм "Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында" 16.01.2015 № 4-ТРЗ Татарстан Республикасы законнарын, " "Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибе пунктларын булдыруның тәкъдим ителгән критерийларын раслау турында" 30.05.2015 № 382 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районында Нурлат шәһәре, Мәктәп урамы, 31 һәм Завод урамы, 17а адресы буенча урнашкан тәртип саклау җәмәгать пунктларын булдыру һәм күрсәтелгән адрес буенча аларның эшчәнлеге өчен биналар бүлеп бирергә.

2. Нурлат муниципаль районында тәртип саклау җәмәгать пункты турындагы нигезләмәне расларга.

3. Нурлат муниципаль районында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларына хезмәт күрсәтү территориясен билгеләргә: үзәк пункт һәм шикәрчеләр микрорайоны пункты.

4. Нурлат муниципаль районында тәртип саклау җәмәгать пунктлары җитәкчеләрен - административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча закон тәртибендә бирелгән тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын билгеләргә.

5. Нурлат муниципаль районында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларында катнашучыларның санын 2 кеше итеп расларга.

6. Нурлат муниципаль районында тәртип саклау җәмәгать пункты җитәкчеләре тарафыннан бирелгән вазыйфаи затларга - тәртип саклау җәмәгать пункты эшчәнлеген тәэмин итүче җирле үзидарә органы вазыйфаи затларына, законнарда билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи затларга, ул вазыйфага билгеләнгән көннән алып бер ай эчендә Нурлат районында тәртип саклау җәмәгать пунктында катнашучыларның персональ составын билгеләргә.

7. Нурлат муниципаль районында тәртип саклау җәмәгать пунктларын "Татарстан Республикасында тәртип саклау җәмәгать пунктларын булдыруның тәкъдим ителә торган критерийларын раслау турында"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.05.2015 № 388 карарында күрсәтелгән матди-техник чаралар белән тәэмин итәргә.

8. Нурлат муниципаль районының 2016 елга һәм аннан соңгы елларга бюджетын рәсмиләштергәндә Нурлат муниципаль районында матди-техник җиһазландыруга һәм тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлегенә чыгымнарны күздә тотарга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин